СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2023 г.Зеленодольск № 113

Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 нче мартындагы 38 номерлы карары белән (Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 26 августындагы 59 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне искә алып) расланган, Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск шәһәре Советы Регламентына туры китереп, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 24 нче мартындагы 38 номерлы карары белән (Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 26 августындагы 59 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне искә алып) расланган, Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статья

1) 1 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, депутатлар Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе сенаторлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкара алмый. Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты бер үк вакытта шәһәр Советы депутаты вәкаләтләрен дә башкара алмый, 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш.»;

2) 2 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында «Президенты» сүзен «Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 5 статья.

1.2.1.4 өлештә 1.2.1 «Президент» сүзен «Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле 1.1 өлеш өстәргә:

«1.1. Шәһәр Советының барлык утырышларында нигезле сәбәпләрсез алты ай рәттән депутат булмаган очракта, шәһәр Советы карары белән район депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»

1.3. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. Депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

1. Әгәр федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) белешмә тапшыралар.

2. Үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы шәһәр Советы депутатлары, депутат булып сайланган көннән алып , керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң, дүрт ай дәвамында белешмәләр тапшыра.

3. Шәһәр Советы депутатлары «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда, Россия Федерациясе законнары нигезендә, керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыра.

Әгәр хисап чоры дәвамында әлеге затның һәм аның хатынының (тормыш иптәшенең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән гомуми суммасы артып китсә, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр башкарылмаса, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы шәһәр Советы депутаты бу хакта, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) хәбәр итә.

4. Шәһәр Советы депутатлары тәкъдим иткән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларга, шәһәр Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар бирү турындагы мәгълүматка керүне тәэмин итү

федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Шәһәр Советы депутатларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны тапшыру бурычы турында гомумиләштерелгән мәгълүмат, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла (мондый мәгълүматта тиешле затны идентификацияләргә мөмкинлек бирүче персональ мәгълүматлар һәм тиешле затныкы булган мөлкәтне индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар булмаганда) .».

2. 1.2.2 пунктының гамәлдә булуы 2023 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**